# Нәсыйхәт

җомга
24
июнь 2011
№ 5

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


# МӘДРӘСӘДӘ – ҖӘЙЛӘҮЛӘР



**Районыбызның 9 яшьтән 14 яшькәчә булган 20дән артык ир баласы 6 июньнән 26 июньгә кадәр мөхтәсибәт белән мәдрәсә берлектә Мамадыш мәдрәсәсендә оештырган лагерьда ял итте.**

Аның максаты балаларга күркәм әдәп-әхлак кагыйдәләрен өйрәтүдән, Хак Тәгаләнең ризалыгына ирешү өчен гыйбадәт кылудан, намазга басарга өйрәтүдән гыйбарәт иде. 26нчы июньдә узган җәйләү ябылу тантанасында балалар әнә шул гыйлемнәрен күрсәттеләр. Кичә изге Коръән аятьләрен уку белән башланып китте. Аны мөгаллимнәр Әмин хәзрәт белән Ирек хәзрәт алып барды. Чарага ата-аналар да күп килгән иде. Малайлар алар алдында шигырьләрен, мөнәҗәтләр һәм башка кызыклы кыйссалар сөйләделәр. Шулай ук тантана вакытында үткәрелгән чараларда беренчелекне алган һәр малайга истәлекле бүләкләр һәм грамоталар тапшырды. Кайберәүләр акыллы, икенчеләре хәрәкәтчән, тырыш, мөстәкыйль һәм башка сыйфатларга ия булып танылу алдылар. Лагерь барышында татар теленә дә күп игътибар бирелде, чаралар да ана телендә алып барылды. Балаларның барысы да туган телдә аралашты. Быелгы малайлар җәйләвендә ун тәрбияче - Асаинов Рамил, Мәгъсүмҗанов Марат, Усманов Вильдан, Зотов Иван, Галимуллин Рөстәм, Кадиев Фаил, Яхин Илгиз, Тимеров Рамил, Гайнетдинов Илһам, Хамматов Ленар эшләде. Алар барысы да – мәдрәсә шәкертләре. Мәдрәсә мөдире Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин фикеренчә, алар үз вазыйфаларын җиренә җиткереп башкардылар, укуукыту тәҗрибәсен уңышлы үттеләр.

***

26нчы июнь көнне мәдрәсә бинасы әйтерсең, аллыгөлле чәчкәләр белән тулган иде. Биредә 8 яшьтән 14 яшькәчә булган кызлар өчен лагерь ачылу тантанасы узды. 25 кыз бала 4нче июльгә кадәр ял итәчәк. Укудан тыш, кызлар өчен мәдәни-спорт программасы да төзелгән, спорт уеннары, походлар, экскурсияләр оештыру да күздә тотыла. Биредә балалар урамның тискәре йогынтысыннан арыналар, рәхәтләнеп ял итәләр, сәламәтлекләрен ныгыталар, дини белем һәм тәрбия алалар, тәртипкә, олыларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр. Алар арасында дуслыклы мөнәсәбәт һәм бер-берәңә мәрхәмәтлелек хисе урнаша.

## Яңалыклар

### Вәкилләребез Болгарда

Берничә дистә ел элек кенә Болгарга качып-посып кына җыела иделәр. Хәзер исә елга бер тапкыр булса да татар мөселманнары өчен бирегә килеп тарихи урыннарны зиярат кылып кайту гадәти эшкә әйләнде. Ә бабаларыбызның Ислам динен кабул итүләрен билгеләп үтү рәсми төсмер алды. 18 июньдә 21нче тапкыр уздырылган Изге Болгар җыены Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче меңәрләгән милләттәшләребезне җыйды. Шул исәптән мәдрәсә вәкилләре дә үткәрелгән чарадан читтә калмады. Тарихи урыннарны күреп, Болгарны зиярат кылып кайттылар.

### Ленар фестивальдә катнаша

Мәдрәсә шәкерте Хамматов Ленар 11 июльдә Казанда узачак мөселман яшьләре фестивалендә катнашачак. Фестивальнең максаты мөселман яшьләрен берләштерү һәм араларында тыгыз элемтәләр булдыру. Программада төрле чыгышлар, очрашулар, түгәрәк өстәлләр һәм башка чаралар каралган.

### Шәкертләр туплана

Мамадыш мәдрәсәсе мөгаллимнәре район авыллары буенча йөрүне дәвам итә. Алар ислам дине белән кызыксынучы балаларга мәдрәсә тормышы турында сөйлиләр, таныштыру-чакыру эшләре алып баралар. Мәдрәсәнең максаты киләчәктә районыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру.

# Тәмәке сине сындырганчы, син аның үзен сындыр…

**Ел саен тәмәке индустриясе 3 миллион кешенең гомерен өзә. Ул 20 реактив самолетның пассажирлары кадәр дигән сүз. Эчкечелек, наркомания кебек, тәмәкечелек тә гасыр авыруы дип атала.**



Эчкечелектән 1 миллион кешедән берсе 4-5 көн саен үлә, тәмәке тартудан исә—һәрбер ике-өч сәгать саен бер кешенең гомере өзелә. Тәмәке тарту һәм эчкечелектән ел саен 3 миллион кеше вакытсыз гүргә керә. Әле бу гына түгел. Әгәр хәлебезне үзгәртмәсәк, Бөтендөнья Сәламәтлек саклау Берләшмәсе мәгълүматлары буенча, ярты миллиард кеше тәмәке тартудан вафат булачак. Бу чынбарлыгыбыз, куркыту түгел. Аллаһ яман гамәлләрдән тыелырга кушып та, кеше тыелмаса, мондый мәгълүматлар гына аны куркытмый. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әйт: «Раббым фәхеш эшләрне күрсәтеп эшли торганын да, яшерен эшли торганын да хәрам кылды, күрсәтеп эшли торганы: су буенда ирләр вә хатыннар бергә су керү, кояшта кызыну кеби эшләр, яшерен булганы — зина кылу эшләредер. Янә гөнаһлы эшләрне, хаксыз золым итү, тәкәбберләнүне, мәхлукны Аллаһыга тиңдәш кылырга ярый дип, Аллаһыдан аять иңмәгән көйгә һәм Аллаһ хакында белмәгәнне сөйләүне хәрам кылды»,—дип.» (7:33). Кызганыч ки, күп кенә үзләрен мөселман дип санаучылар исламда тәмәкенең тыелганын аңламыйлар яки аңларга да теләмиләр. Кайберәүләр болай дип акланыр: «Моның хакында Коръәндә дә, сөннәттә дә бернәрсә дә язылмаган». Әйе, турыдан-туры тыю юк, чөнки ул вакытта тәмәкеләр булмаган. Ләкин Коръәндәге кайбер кагыйдәләр тәмәкегә дә кагыла. Аның гөнаһын раслый торган унлап дәлил бар. Мәсәлән, исраф итү (бер сигарет 25 сум торса, шуны 365 көнгә тапкырларга кирәк), сәламәтлеккә зыян килү (бер тәмәке кешенең гомерен 12 минутка кыскарта). Билгеле булганча, кеше организмы Аллаһның бер нигъмәте, шуңа күрә кыямәт көнне аның өчен Аллаһ каршында җавап бирәчәкбез. Тәмәкенең составында булган никотин һәм башка матдәләр организм өчен зыянлы. Шуңа күрә, тәмәке тарткан өчен бәндә Аллаһ каршында каты җавап тотачак. Шулай ук, бу мәсьәләнең матди ягы да бар. Тәмәке сатып алыр өчен кешеләр күп кенә акча түгә, ләкин шул ук акчаларны күпме файдалы әйбер сатып алыр өчен кулланып булыр иде! Тәмәке алыр өчен, хәтта бәндә тормыш өчен иң кирәкле ризыкларны да алмыйча кала. Бу түбәндәге аятькә каршы килә: «Ий Адәм балалары! Һәр сәҗдә кыла торган урында гаурәтләрегезне каплар өчен зиннәтле киемнәрегезне алып киегез, ашагыз вә эчегез, ләкин исраф кылмагыз, тәхкыйк, Аллаһ исраф итүчеләрне сөйми» “Әгъраф” (7:31). Пәйгамбәребез исә сәламәтлекне саклау хакында берничә хәдистә әйткән. «Дүрт нәрсә хакында җавап бирмичә, кеше беркая да китми. Беренчедән, гомереңне ничек үткәрдең? Икенчедән, гыйлемеңне ничек кулландың? Өченчедән, малыңны кая кулландың? Дүртенчедән, сәламәтлегеңне ничек кулландың?» (Хәким, ибн Хиббан). Хәдистән күренгәнчә, мөселманнар үз сәламәтлекләрен кайгыртырга тиешләр. Алар организмга зыян китерүче нәрсәләрдән тыелырга тиешләр. Әлбәттә, бу сүз тәмәкегә дә кагыла. Икенче хәдистә исә мөселманның гамәленнән һәм сүзеннән башка кешеләр зыян күрмәскә тиешләр, диелгән. Тәмәке тартучы башка кешеләргә дә зыян ясый. Бу күренеш иҗтимагый урыннарда киң таралган.

**ИСЛАМ ТӘМӘКЕ ТАРТУНЫ ТЫЯ**

Бу нәрсәләрне исәпкә алып, кайбер галимнәр тәмәке тартуны хәрамга (зур гөнаһ) чыгаралар. Икенче галимнәр исә мәкрүһ дигән фикер йөртәләр. Шик юк, тәмәке тарту гөнаһлы гамәлләр рәтенә керә. Исламда гөнаһ саналган нәрсәләрне сату да гөнаһлы гамәл була. Аллаһы Тәгалә әйтә: «...янә сез уйлыйсыз ул җиңел эш, анда гөнаһ юк дип, әмма Аллаһ хозурында ул зур эшдер, азабы каты булыр» («Нур», 15). Кайбер тәмәкечеләр аны начар гадәт дип кенә атыйлар. Ләкин түбәндәге дәлилләр тагын бер кат начар гадәт кенә түгел, ә гөнаһ икәнлегенә ышанырлар. Тәмәкечелек —гөнаһны ачыктан-ачык кылу. Аллаһ илчесе әйтә: «Ачыктан-ачык гөнаһ кылып йөрүчеләрдән башка, өммәтемдә бөтен кешенең дә гөнаһлары кичерелә». Синең тәмәке тарканыңны күрүче һәркем Кыямәт көнне сиңа каршы сөйләр. Сиңа каршы булачак шаһитләрне санап бетерә аласыңмы? Тәмәке тарту – гөнаһ кылу нияте. Тәмәкече алдан ук тәмәкеләр сатып ала. Юлга чыкса, берничә кап алып куя. Ибн Габбас әйтә: «Әгәр аның артыннан тәүбә булса, зур гөнаһ юк; әгәр ул еш кылынса, кечкенә гөнаһ юк». Тәмәкечелек — еш гөнаһ кылу. Тәмәке тартучы берсен тарткач, шунда ук икенчесе хакында да уйлый. Ул бит акрын гына үз-үзеңне үтерү дигән сүз. Бөтен табиблар да тәмәкенең агу икәнлегенә ышана. Аллаһ әйтә: «Аллаһ каршында сәдакалар бирегез, үз-үзегезне үтермәгез. Изгелек кылыгыз, чөнки Аллаһ изгелек кылучыларны сөя». Тәмәке зыян итмәгән әгъзаны табу авырайганнан-авырая бара. Япон галимнәре раславынча, тәмәке тартучының үзенә генә түгел, ә нәселенә дә зыян итә икән. Ана карынында ук зыян салырга мөмкин. Ир-атның У-хромосомалары хатын-кызларның Х-хромосомаларына караганда тәмәкегә ныграк бирелә. Күзәнәкләр үлә, шуңа күрә, тәмәкече ир-атның баласы булмаска да мөмкин икән. Тәмәке тартучы хатын-кызның да баласы булмаска мөмкин.

***ГАБДРАХМАН ХӘЗРӘТ ХӘБИБУЛЛИН.***

**«Ий Адәм балалары! Һәр сәҗдә кыла торган урында гаурәтләрегезне каплар өчен зиннәтле киемнәрегезне алып киегез, ашагыз вә эчегез, ләкин исраф кылмагыз, тәхкыйк, Аллаһ исраф итүчеләрне сөйми» “Әгъраф” (7:31).**

# Алган гыйлемнәр файдалы булсын!

**24 июнь, җомга. Бүген икеләтә бәйрәм. Ник дигәндә: бу көндә мәдрәсәдә өч ел буе гыйлем алучы хатын-кызларга һәм ир-атларга шәһадәтнамәләр тапшырылды.**

Алар мәдрәсәнең беренче карлыгачлары. Ошбу апаларның һәм абыйларның араларында берничә диплом ияләре дә бар мөгаен, әмма бүгенге көн аларга аерата дулкынландыргыч һәм аерата якын. Чөнки алар өч ел дәверендә мәдрәсәгә килеп гыйлем тупладылар. Гади генә гыйлем түгел – ахирәт гыйлеме. Аларның һәммәсенең бу дөньяда яраткан эшләре, балалары, оныклары, яши торган йортлары, утырып йөри торган машиналары бар... Әмма берсенең дә ахирәттә җәннәтле булырсың дигән гарантия кәгазьләре юк. Пәйгамбәребез с.г.в.нең бер хәдисендә гыйлем хакында " Бер кеше гыйлем эстәү нияте белән юлга чыкса, Аллаһ аңа җәннәт юлын җиңел кылыр. Гыйлем эстәүче кеше риза булсын өчен, фәрештәләр канатларын куеп торырлар (хөрмәт күрсәтерләр). Гыйлем эстәүче кеше өчен күктә вә җирдә булганнар, хәтта судагы балыклар да истигъфар кылырлар,"-диелә. Нәкъ шуның өчен дә алар бирегә-нурлы мәдрәсәбезгә килеп, җәннәткә якынаям дип, Раббыбыздан ярлыкау сорыйм дип, армый-талмый, буран дими, яңгыр дими, гыйлем тупладылар. Болар – иң гүзәл, иң тырыш, акыллы ханымнар һәм абыйлар. Аларның мәдрәсәгә йөреп өч ел укулары бушка үтмәде. Алар Коръән-Кәрим китабын дөрес уку серләренә төшенеп, пәйгамбәребез с.г.в.нең тормышы, хәдисләре белән танышып, фикх, гакыйдә, гарәп теле кебек фәннәрне өйрәнделәр. Алар бүген аерата бәхетле. Чөнки Аллаһының иң бөек Китабын кулга алып дөрес итеп укый алалар. Раббылары алдына килеп дөрес итеп дога кылып, дөрес итеп намаз укый алалар. Бу исә чын бәхет һәм зур казаныш. Ә бит бүген күпме әле адашып, саташып йөрүче ханымнарыбыз һәм ирләребез, күпме үз кыйбласын онытып, бозык юлга кереп киткән милләттәшләребез, Раббыларын онытып нәфес колларына әверелгән якташларыбыз...

Әйе, өч ел сизелми дә узып китте. Бүген кулларда шәһадәтнамәләр, йөзләрдә әйтеп бетергесез шатлык. Алган гыйлем файдалы булсын өчен аны гамәлгә ашырырга кирәклеген дә онытмаска кирәк. Гыйлем гамәлдә чагылыш тапкан очракта гына ул чын мәгънәдә файдалы була ала. Пәйгамбәребез әйтүенчә: "Иң яхшы гамәл–әз булса да дәвамлы булганы,"- ди. Гыйлем алуыбыз да дәвамлы булса, ул тагын да нәтиҗәлерәк булачак. Мәдрәсәбезнең беренче чыгарылыш шәкертләре дә киләчәктә дә дини укуларын дәвам итәрбез дип сүз куештылар. Амин, шулай булсын!

Мәдрәсәбез укучылар белән тулып торсын, Аллаһ Раббыбыз үз рәхмәтеннән ташламасын!

## Сорау илә җавап

### Намаз укымаган мөселман имансызга әйләнмиме?

**Юк, имансызга әйләнми. Әгәр кеше Аллаһ һәм Аның соңгы Пәйгамбәре, барлык фарыз гамәлләр белән килешсә, аларны кире какмаса, мөселман булып саналуын дәвам итә. Ә бер мәҗбүри дини гамәлне үтәмәүче гөнаһлы бәндә дип исәпләнә. Әгәр ул үзенең ялкаулыгы, ихтыяр көченең зәгыйфьлеге, дини белеме булмавы нәтиҗәсендә фарыз гамәлләрнең барысын да үтәп бетерә алмаса, бу аның иманының зәгыйфьлеген һәм Аллаһка җитәрлек дәрәҗәдә бирелмәгәнлеген күрсәтә. Раббыбызга ышануын үстерә башлаганчы һәм дини гамәлләрне җиренә җиткереп үтәгәнче ул кешенең иманы куркыныч астында дип уйланыла.**

# Фәрештәләрне качырма

**Күптән түгел, «Пәйгамбәрләр тарихыннан» китабында бер риваятькә тап булдым. Мөшрикләр (купаллалыкны танучылар) Ибраһим г.с.не, бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбәдәт кылырга өндәгәнгә, утка ташларга уйлыйлар.**

Зур учак ягып пәйгамбәрне катапультага утыртып, утка ыргытырга ниятлиләр. Ләкин күпме генә тырышуларына карамастан, техникалары эшләми. Шуннан сон, шайтаннар башлыгы Иблис әйтә: «Монда булган бөтен хатын-кызларның башларындагы яулыкларын салдырыгыз, җиңнәрен тартып ертыгыз». Ирләр барысын да Иблис әйткәнчә башкаралар. Һәм техника хәрәкәткә килә. Моңа кадәр катапультаны хәрәкәтсез рәвештә тотып торган фәрештәләр, хатын-кызларның башлары һәм куллары ялангач калуга, бу урыннан качалар. Иблис бу хикмәтне белгән була. Ләкин Раббыбыз учакны гөлбакчага әйләндереп өлгерә һәм Ибраһим с.г.не утка ташлаттырмый.

Бу риваять бик тирән эчтәлекле. Әйдәгез, бергәләп аның мәгънәсенә төшеник.

Арабызда бишвакыт намаз укымаучы, ураза тотмаучы, зәкәт түләмәүче (димәк, Аллаһның ризалыгына, рәхмәтенә һәм җәннәтенә ирешергә теләмәүче) кешеләр бихисап. Ләкин, Коръән мәҗлесләре, мәрхүмнең өчесен, җидесен, кырыгын уздырмаган, яки анда катнашмаган кеше юктыр, дип уйлыйм. Һәр мәҗлестә Коръән укыла. Коръән укылган жиргә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт фәрештәләре төшә. Алар Коръән укучыга да, ашта утыручыга да хәер-дога кылып торалар. Коръән уку тәмамлангач, фәрештәләр догаларыбызны Аллаһы Тәгалә кабул кылыр дип өметләнәләр. Без дә укучы имам, я абыстайга кушылып, догаларыбыз, уздырган ашларыбыз кабул булсын дип, кат-кат дога кылабыз. Ләкин догалар кабул булырмы, юкмы дип аштан соң түгел, бәлки иртәрәк уйланырга кирәктер. Риваятькә нигезләнеп шуны әйтергә була: ашта утыручы, табын әзерләүче, вак-төякне хәстәрләүче хатын-кызларның берсе генә дә тиешле (гаурәтләрен каплаучы) киемнән булмаса, фәрештәләр аштан курып качалар, янә килмиләр. Димәк, догаларыбызның кабул булуына да шик туа.

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз! Ашка барсак, яисә шул ашны әзерләүдә булышсак, чәч күренмәслек итеп матур яулыкларыбызны бәйлик, озын җиңле күлмәк киеп (ул һәркемнең гардеробында бардыр), түшләребезне каплап барыйк. Теләге булган кеше мәҗлес өчен аерым кием тектерергә, сатып алырга мөмкин. Бу саваплы да, файдалы да: ашка да, мәчеткә дә еш барырга туры килә, матур һәм чиста кием һәрвакыт әзер торса, үзебез үк рәхәтен татырбыз. Концертларга, бәйрәмнәргә барыр өчен өстенә-өстенә, кат-кат кыйммәтле күлмәкләр алабыз бит. Ашка йөрергә дип тә бер матур кулмәк алганнан, акча янчыгыбыз артык юкармас. Аллаһы Тәгаләнең яулык бәйләп, гаурәтләребезне капларлык итеп киенергә кушкан әмерен үтәргә никтер ашыкмыйбыз. Ичмасам ашларда, мәчетләребездә, зиратта булганда, үзебезне дөрес итеп тотыйк, таләпләргә карап киеник. Чөнки Коръән укуның, аш уздыруның, күпме көч, вакыт һәм мал сарыф итүнең савабы шушы сәбәпләр аркасында булмаска, яисә күпкә кимергә мөмкин. Тырышлыкларыбызны җилгә очырмыйк, ашларга матур итеп киенеп килик, гайбәт сөйләмичә, дөнья малына сатылмыйча, бары урынлы, күңелгә ятышлы сүзләр сөйләп, һәм дә ашларыбызны бары хәләл ризыктан әзерләп уздырыйк.

Ашлар уздырганда бу киңәшләрне игътибарсыз калдырмассыз дип уйлыйм. Шушы язманы укып туганнарыгызга, күршеләрегезгә, таныш-белешләрегезгә сөйләсәгез, яки ксерокс аша чыгарып ук бирсәгез, күп савапка ирешерсез. Аллаһы Тәгалә үзенең рәхмәтеннән ташламас.

*ГҮЗӘЛ ИБРАҺИМОВА,*
*мәдрәсәнең икенче курс шәкерте.*

## Багучыга барма– башыңа бәла алма!

Яши бүген безнең
арабызда
Күрәзәче–күрә белүче.
Әз-мәз генә кулын
болгаштырып
Шайтаннарны эшкә җигүче.
Дөнья тулган хәзер
алар белән,
Кемгә барып микән уңасы?
Багучыга баручының
40 көнсез
Кабул булмый икән догасы.
Аңа халык иртән
агыла башлый,
Шактый акча
чыгарып ташлый:
–Машина кирәк,
кайсын аласы?
–Ничек миңа бай
кияү табасы?
–Эч сыкрый, ничек
дәва табыйм,
Нәрсәдән мин бүген сихәт
алыйм?
–Ярдәм итсәң иде,
синдә өмет,
Бары исән генә калыйм!
Тик барыбер саулык
никтер килми,
Сыкрап үтә көннәр
һәм айлар.
Аллаһ тәкъдиреннән качып,
Исән калыр иде
бар байлар.
Аңда туган бер
сорауга, күңел
Төгәл генә җавап
таба алмый:
“Эч сыпырып,
бала була алганны”,
Баш очында торган
яңгыр болытыннан,
Ни өчендер
яңгыр ява алмый?
Шайтан урлый
күктән Аллаһ сүзен,
Ялчысына
китереп җиткерә.
Урланган белән
яшәү намуслыга
Вөҗдан газаплары китерә.
Ялгыш кына кайчак алсак,
Килә хуҗасына
тизрәк бирәсе.
Бөек Аллаһ хозурыннан
урлап,
Яшәгәндә ниләр күрәсе!
Бөек Аллаһ
бары хәбәр биргән
Пәйгамбәргә, хак
дин илтсенгә.
Бәндәләрен, шайтан
коткысыннан йолып,
Бер Аллаһка итәгать
итсенгә.

..................................

ӘЛФИРӘ ХАҖИЕВА.

**Көлсәң, көл**

## Мөрит

**Рамазан шәрифтә бер Мөритнең бик ифтар итәсе килде.**

Мөрит, бу турыда уйламыйча, бер караңгы бүлмәгә кереп, шәм яндырды да шәмгә тотып йомырка пешерергә тотынды. Йомырка пешкәч, кабыгын әрчеп ашарга гына башлаган иде, кисәктән күзе алдында үзенең шәйхе пәйда булып: “Бу ни гөнаһ!”–дип кычкырды. Мөритнең курыкканлыктан тәне тотылып: “Хәзрәт, зинһар, кичерә күр, шайтан котыртты... кот... котырткан иде”,–дигәндә, мич астыннан бер шайтан баласы сикереп чыкты да, Мөриткә карап: “И оятсыз! Син нәфесең теләгән эшне эшлисең дә, һаман без шайтаннарны гаеплисең; мин әле шәмгә тотып йомырка пешерүне үзем дә синнән генә өйрәндем”,–диде.

***Мөрит–ишанга ияргән кеше.**

***ГАБДУЛЛА ТУКАЙ.***

Газетабызның 4нче санында басылган викторина җаваплары

1.Ике арпа орлыгын төенләп бәйләргә кушарлар. 2. Колакларына эретелгән бакыр агызырлар. 3.Пальма. 4.Көрәеш кабиләсе. 5.Әбү Җаһил. 6.Бахира. 7.Гомәр ибн Хаттаб. 8.10нчы елда. 9.Һәмзә. 10.Сәмуд. 11.Дөя. 12. Ур шәһәре, Гыйрак җирлеге. 13.Яхья. 14. Тур тавы зурлыгында. 15. Азба.

## Фольгада пешкән бәрән ите

**3 кисәк бәрән ите (филенең сөякле өлеше кулайрак), 1 помидор, 3 аш калагы туралган яшь суган, 1 чәй калагы орегано, 1 аш калагы үсемлек мае, 1 аш калагы лимон согы, 50 г сыр, тоз, кара борыч.**

Бәрән итенә тоз, борыч, тәмләткечләр, лимон согы, сыек май сибәбез. Шушы маринадта 1 сәг. тотабыз. Әзер итне фольгага урнаштырабыз, өстенә помидор, вак итеп туралган суган, терка аша чыккан сыр сибәбез һәм кызган духовкага урнаштырабыз. Әзер булгач, фольганы ачып, өстенә вак итеп туралган яшел укроп һәм петрушка сибеп табынга куябыз.

## Кара җимеш белән бәрән ите

**750 г бәрән ите, 1 зур башлы суган, 1,5 аш калагы сыер мае, 1 тулып бетмәгән аш калагы он, пычак очында корица, 120 г кара җимеш, 1 чәй калагы шикәр комы, тоз, борыч.**

Итне вак (1*5 см) кисәкләргә турыйбыз. Суганны табада җинелчә кыздырабыз, янына итне кушабыз. Өстенә он, тәмләткечләр сибәбез, яхшылап болгатабыз. Өстен каплаганчы кайнар су сибәбез, салмак утта пешерәбез. Әзер булырга бераз вакыт калгач, кара җимеш, шикәр комы өстибез. Кара җимешне алдан җылы суда 12 сәг. тотабыз, төшен алабыз. Өстәлгә уалып торган дөге белән бирергә, яшеллек белән бизәргә мөмкин.

## Бәрән итеннән кебаби

**500 г бәрән ите, 75 г эчке май, 1 йомырка, ¼ чәй калагы төелгән кара борыч, башлы суган, барбарис, тоз.**

Бәрән ите, эчке май, башлы суган, барбарисны ике тапкыр иттарткыч аша чыгарабыз. Шушы фаршка тоз, борыч, йомырка кушып, яхшылап болгатабыз. Учакта кызган шампурларга, кечкенә овал шарчыклар итеп, әйләндергәләп, әзер булганчы кыздырабыз. Табынга һәрберсен ләвәшкә төреп бирәбез, өстенә вак итеп туралган суган кыягы, төелгән барбарис, гранат төшләре сибәргә мөмкин.

## Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

**МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕ КИЛӘСЕ 2011 - 2012 УКУ ЕЛЫНА** шәкертләр туплый. Мәдрәсәгә тугызынчы сыйныфны тәмамлаган ир-егетләр кабул ителә. Дәресләр кичке уку рәвешендә алып барылачак. Документларны кабул итү 1 июльдән башлана. Шул исәптән Мамадыш мәдрәсәсе яше чикләнмәгән ир-ат һәм хатын-кызларны кичке уку бүлекләренә укырга чакырып кала. Беренче курска килүчеләрдән түбәндәге документлар таләп ителә:

1.Гариза (мәдрәсә бланкасына тутырыла)
2.3 х 4 зурлыгындагы 4 данә аклы - каралы фоторәсем;
3. Белем таныклыгының копиясе;
4. Паспорт копиясе;

1 курска кабул ителгән ир-егетләрнең уку лары 2 сентябрьдә сәг. 16:00 дә ә ир-ат һәм хатын-кызларның укулары 3 октябрьдә сәг. 17:00 дә башланачак. Мәдрәсәбезгә рәхим итегез!

**ҮЗЕБЕЗНЕ РУХИ РИЗЫКТАН МӘХРҮМ ИТМИК!**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**